Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Иске Михайловка авыл Советы

КАРАРЫ

«27 » сентябрь 2021 ел № 23

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы «Иске Михайловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы 14 статьясы 3 өлеше, Әлмәт муниципаль районының « Иске Михайловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру өлешендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2015 елның 6 маендагы 468 номерлы карары белән расланган Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән килешү төзү (кабул итү) тәртибе нигезендә

Иске Михайловка авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. 1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының « Иске Михайловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен, шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча, Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү, рөхсәтсез төзелгән корылманы җимерү яисә билгеләнгән таләпләргә туры китерү хакында карар кабул итү өлешендәге җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, территорияне планлаштыру документлары яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләр белән билгеләнгән вәкаләтләрен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советына карарга җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге» бюджетыннан Россия Федерациясе гражданлык

законнары нигезендә, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү, рөхсәтсез төзелгән корылманы җимерү яисә билгеләнгән таләпләргә туры китерү хакында карар кабул итү өлешендәге вәкаләтләрен тормышка ашыру буенча бюджетара трансфертларын ачыклауны тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Иске Михайловка авылы торак пункты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнвареннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Иске Михайловка авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Иске Михайловка авыл
җирлеге башлыгы И.М.Абдуллин